Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының унсигезенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

9 декабрь, 2021 ел № 126

«2020 - 2024 елларга Питрәч муниципаль районы яшьләрен патриотик тәрбияләү» район программасын гамәлгә ашыру барышы турында

Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарының «2020 - 2024 елларга Питрәч муниципаль районы яшьләрен патриотик тәрбияләү» район программасын (алга таба - Программа) гамәлгә ашыру барышы турында мәгълүматын тыңлап **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Программаны гамәлгә ашыру барышын канәгатьләнерлек дип танырга.

2. Питрәч муниципаль районы башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

2.1. тәэмин итәргә:

- 2022 - 2024 елларга планлаштырылган Программаның тулы күләмдә чараларын гамәлгә ашыру;
- авыл җирлекләрендә яшьләрне патриотик тәрбияләү буенча массакүләм чаралар системасын үстерү;

2.2. ярдәм итәргә:

- район акцияләрен һәм патриотик юнәлешле чараларны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген күтәрүгә;
- укучылар һәм яшьләр арасында лидерларны ачыклау, аларны җәмәгать балалар һәм яшьләр оешмалары эшчәнлегенә җәлеп итү.

2.3. «Вперед» («Алга») газетасы һәм «Интернет» челтәрендә хәрби-патриотик берләшмәләр эшчәнлеген һәм патриотик тәрбия буенча чаралар уздыруны яктыртырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының социаль мәсьәләләр, сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният һәм яшьләр эшләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов

СОВЕТ ПЕСТРЕЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА